ГЛАВА
ЯЛКЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯЛКЫН АВЫЛ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.10.2021** д. Ялкын **2**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Ялкын авыл җирлегенең Караваево авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясындагы 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Уставының 23` маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 108 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлегенең Караваево авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 11 ноябрендә 15:00 сәг. билгеләргә.

Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан АК бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Караваево авылы, Мәктәб ур., 3 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына

ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм төзекләндерү;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу;

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Ялкын авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Ялкын авыл җирлеге башлыгы** **И.В.Гущина**